

Мин, Лутфиева Шәмсия Вагыйзовна Минзәлә районы (хәзерге Тукай районы) Калмия авылында 1936 елның 7 ноябрендә дөньяга килгәнмен. Әтием Лутфиев Вагыйз, әнием Лутфиева Миннур.

Калмия авылында башлангыч мәктәпне 1-4 сыйныфны тәмамлагач, бездән 8 км ераклыктагы Кузкәй урта мәктәбенең 5 сыйныфына укырга кердем. Көндә 8 километрны җәяу барып кайтып (16 километр) йөреп 10 сыйныфны тәмамладым. Ул вакытларда интернатлар юк иде.

Әтием миңа 4,5 яшь булганда Ватан сугышының 1 нче көннәренннән ук сугышка китә һәм Мәскәү өчен барган каты сугышларда -1941 елның 25 декабрендә вафат була.

10 сыйныфны тәмамлагач Минзәләнең өч еллык медицина училищесына керү имтиханнарын уңышлы тапшырып, укырга кердем. Училищены тәмамлагач юллама (направление) буенча Менделеевский районы Бәзәкә авылына фельдшер булып эшкә килдем. Бәзәкә авылында 40 ел фельдшер булып эшләп лаеклы ялга чыктым. Фельшерның бер ел эшләве - ел ярымга хисаплана закон буенча, шуңа минем эш стажым 60ел булып хисаплана. Авыл зур, 1500 халык яши иде. Эш күп кырлы, киеренке, үтә дә җаваплы һәм тынгысыз булды. Эш сәгате (не нормирован) нормага куелмаган. Бәзәкә колхозы составына тагын курше дүрт авыллар да керә иде. Бу авылларда медпунктлар булса да,эшләүче медиклар булмады. Шуңа

күрә миңа ул авыллардагы тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, елның теләсә кайсы фасылында барып ярдәм күрсәтергә, эшләргә туры килде (бушлай). Эшләү дәверендә һәрвакыт җәмәгать эшләре дә алып барырга туры килде. Агитатор, берничә ел рәттән авыл советы депутаты булып сайландым. Клубларда, мәктәптә, терлекчеләр, механизаторлар алдында, медицина темасына лекцияләр укырга туры килде. Халык сәламәтлеген саклаудагы һәм ныгытудагы хезмәтләр өчен берничә мәртәбә ТССР сәламат лек саклау министрлыгының, район советының Мактау кәгазъләре белән бүләкләндем.

1.28.05.1991ел.     I категория фельдшер исеме бирелде.

2.1969-1989ел. Авыл советы депутаты

3.1970 ел. Почетный донор .

4.Юбилейный медаль “За доблестный труд” 100 летие В.И.Ленина.

5.24.03.1988 ел ТАССР за долголетний добросовестный труд от имени Президиума Верховного Совета СССР награжден медалью “Ветеран труда”.

6.Военный офицер запаса –младший лейтинант мед.службы 1968 елдан бирле.

7.1945-1995 ел. Сугыш беткәнгә 50 еллыкка “Юбилей медале” белән бүләкләндем.

8.2016 ел. Бәзәкә авылынын ”почетлы гражданы”.




Медицинада озак еллар фидакарь хезмә-
те, кече ватаны Бәзәкә авылына һәм аның
кешеләренә тугрылыгы, шәфкатьлелеге,
мәрхәмәтле йөрәге һәм бары тик игелек кылыр-
га омтылуы өчен
бүләкләнә
«Алтын йөрәкле кеше»
Лотфиева
Шәмсия Вагыйзовна,
сәламәтлек саклау һәм хезмәт ветераны


БИЗЯКИ
УДОСТОВЕРЕНИЕ
К НАГРУДНОМУ ЗНАКУ
«ПОЧЕТНЫЙ ГРАЖДАНИН
БИЗЯКИНСКОГО
ЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ»



Этием фотосы

Бөек Җиңүнең 65 еллыгына

# КАЙТАЛМАДЫҢ, ӘТКӘЙ...



**Кулымда – вакыт зилзиләләрендә таушалган яшькелт дәфтәр бите. Бу – кызылармияче Вагыйз Лотфиевның фронттан язган соңгы хаты.**

Р.МИРЗАЯНОВА

Хат ил солдатының кызы Шәмсиядә иң кадерле ядкарь булып саклана. Хәбәрне җибәрү датасына күз салам: 1941 елның 25 декабре. 69 еллык хатта – ул вакыттагы кечкенә кызның, хәзер инде чәчләре чаларган өлкән яшьтәге апаның борчу-кайгылары да әтисен юксыну ачысы да.

Вагыйз Лотфиев тумышы белән Минзәлә районыннан. Бераз белеме булган, укый-яза белгән ир колхозда бригадир вазифаларын башкара. Фин сугышын үткән Лотфиев эшче-крестьян армиясенең гамәлдәге кадрлар службасында тора, 1940 елның гыйнварыннан запастагы укчылар полкында исәпләнә.

Шуңа күрә, сугыш башлангач та, Вагыйз фронтка беренчеләрдән булып алына. Бу турыда Шәмсия ханым миңа нәрсәләр сөйли: "Миңа ул вакытта биш яшьләр тирәсе иде. Әтием мине күтәреп алып күкрәгенә кысты, бер кулы белән әнине кочаклады: "Сугыш озак бармас, тиздән дошманны җиңеп кайтырбыз, диде".

Солдат ил иминлеген якларга китә, гаилә ут эчендә кала. Хәзер бригадирлык эшен әниләре башкара. Инде авылга шомлы хәбәрләр – беренче похоронкалар да килә. Лотфиевлар өмет белән яшиләр. Ниһаять, күптән көтелгән хәбәр! "Исәнмесез! Сезки кадерле булган әткәй белән әнкәйгә күп сәлам җибәреп, сәламәт яшәвегезне теләп калам. Миңнур кадерлем, кызларым Шәмсия һәм Тәзкирә, сезгә дә сәлам. ... Без, Мәскәүне узып, Калинин өлкәсенә килдек. Минем белән бер ротада Камай авылыннан Зиннәтуллин дигән берәү бар. Кадерлеләрем, минем өчен кайгырмагыз. Немецларне совет җиреннән куып юк иткәч, өйгә кайтырбыз. Бик сагындым сезнең барыгызны да, эх, бер күрешәсе иде... Хушыгыз, сәлам белән Вагыйз. 25/XII-1941".

Хатны укыгач, гаилә башлыгының исән икәнлеген белгәч, Шәмсиянең һәм әниләренең күңелләренә бераз шатлык иңә. Ләкин куанычлары озын гомерле булмый шул. Кызылармияче Вагыйз Лотфиев хәбәрсез югала. Шәмсия, бераз исәя төшкәч, әтисен төрле чыганаклар буенча эзләтә, ләкин һәркайдан бер үк җавапны ала: "Сез эзләгән кеше үлгәннәр, яралардан вафат булганнар, хәбәрсез югалганнар исемлегендә юк".

Хәтер – мәңгелек, диләр. Бәзәкә авылында яшәүче Шәмсия Лотфиева өчен дә шулай. Шәмсия Вагыйзовна озак елар фельдшер-акушерлык пунктында фидакарь хезмәт куйды. Бәлки аны медицинага әтисен табасы, аңа ярдәм итәсе килү теләге китергәндер? Ерак араларны якын итеп булса да каберенә барып чәчәкләр куясы, сөекле әтисенең изге рухына багышлап дога укыйсы килү гомере буе җанын тырнап, йөрәгеннән кан саркытып тора бит.

Әйе, сугыш Шәмсия апа кебек бик күпләрнең балачагын урлады, күпләрне ятим калдырды. Ә өмет дигәнең һаман йөрәкне алгысыта: бәлки, могҗиза беләнме, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме беләнме, Ватан солдаты Вагыйз Лотфиев турында берәр хәбәр ирешер, я күмелгән урыны табылыр?

Илебез Бөек Җиңүнең 65 еллыгын каршыларга әзерләнә. Ул елларның кайтавазы, ветераннар белән бергә, сугыш чоры балаларының да күңелендә чагыла. Безнең изге бурычыбыз – аларны онытмау, кадер-хөрмәт күрсәтү.

# Сәлам хаты

Исәнмесез. Сезки кадерле булган әткәй һәм әнкәйгә күп сәлам җибәреп, сәламәт яшәвегезне теләп калам. Миңнурга (хатыны), Шәмсиягә үскән кызга, Тәзкирәгә (кече кызы, ун яшендә үлгән) бик күп сәлам җибәреп калам. Сеңлем Сәлимәгә һәм Сәгъдиягә күп сәлам.

Үзем хәзергә сау-сәламәт. 21/XII дә поезда килеп төштек. Мәскәүдән 5 км китеп, менә бер бик яхшы йортның квартирында кунабыз... (танып булмый). Мәскәүне узып 600 км китеп Калининская областьта туктадык. Город Аста(ы)шковага 20 км калды. Әле безнең часть килеп җитмәде. Бүген килеп бетәр ахры. Аннан соң шуннан фронтка керәләр ахрысы. Минем белән бер ротада Камай авылыннан Зиннәтуллин дигән берәү бар, 1907 елгы. Минзәләдән Медведев дигән кеше бар. Әле ул авырыбрак тора. Мин сезгә берничә хат салган идем, тик сездән җавап алып булмады. Бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәнгәдер инде.

Кадерлеләрем, минем өчен кайгырмагыз. Немецларне совет җиреннән куып юк иткәч, өйгә кайтырбыз. Бик сагындым сезнең барыгызны да, эх, бер күрешәсе иде. Ярый, хат языгыз, шул минем адрес белән. Килсә килер, килмәсә юк. Хат язылды 25/XII-41 ел.

Бүген төштә әнкәй белән әткәйне күрдем. Үзем тегермән тартып өйгә он алып кайтып бушаттым. Шакирҗан бабайны да күрдем. Балык ашарга чакырды.

Хушыгыз. 25/XII-41

Сәлам белән Вагыйз.

# Имин генә булсын дөньяла




**Саргаеп, таушалып, инде ертылып та баручы бу хатны мин зур саклык белән генә кулларыма алдым. Ялгыш өрсәң яки саксыз орынсаң да уалырга торган солдат хаты...**



## 63 ел гомерле хат

Башта фин сугышында катнашкан. 1941 елда, сугышның беренче аенда ук, фронтка китте. Миңа ул вакытта биш яшьләр тирәсе иде. Хушлашканда мине, әнинең алъяпкычына капланып ыбрак торган кызын, күтәреп алды да, күкрәгенә кысты. Әни елап җибәрде. «Еламагыз, без кайтырбыз, озакка бармас бу сугыш»,—диде әти. Бу аның без ишеткән соңгы сүзләре булды.

Шәмсия апа бермәлгә тынып калды. Кулындагы хатка озак кына карап торды да:

—Ярты гасырдан артык узса да, күп сүзләрен әле танып була. Телисең икән, мә, укы,—диде.

Менә ул—яу кырыннан 63 ел элек язылган солдат хаты.

### Сәлам хаты

*Исәнмесез. Сезки кадерле булган әткәй һәм әнкәйгә күп сәлам җибәреп, сәламәт яшәвегезне теләп калам. Миңнурга* (хатыны), *Шәмсия—ускән кызга, Тәзкирәгә* (кече кызы, ун яшендә үлгән) *бик күп сәлам җибәреп калам. Сеңлем Сәлимәгә һәм Сәгъдиягә күп сәлам.*

*Үзем хәзергә сау-сәламәт. 21/XII дә поезда килеп төштек. Мәскәүдән 5 км китеп, менә бер бик яхшы йортның квартирында кунабыз...* (танып булмый). *Мәскәүне узып 600 км китеп Калининская областьта туктадык. Город Аста(ы)шковага 20 км калды. Әле безнең часть килеп җитмәде. Бүген килеп бетәр ахры. Аннан соң шушыннан фронтка керелер ахрысы. Минем белән бер ротада Камай авылыннан Зиннәтуллин дигән бергәү бар, 1907 елгы. Минзәләдән Медведев дигән кеше бар. Әле ул авырыбрак тора. Мин сезгә берничә хат салган идем, тик сездән җавап алып булмады. Бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәнгәдер инде.*

*Кадерлеләрем, минем өчен кайгырмагыз. Немецләрне совет җиреннән куып юк иткәч, өйгә кайтырбыз. Бик сагындым сезнең барыгызны да, эх, бер күрешәсе иде. Ярый, хат языгыз, шул минем адрес белән. Килсә килер, килмәсә юк. Хат язылды 25/XII-41 ел.*

*Бүген төштә әнкәй белән әткәйне күрдем. Үзем тегермән тартып өйгә он алып кайтып бушаттым. Шакирҗан бабайны да күрдем. Балык ашарга чакырды.*

*Хушыгыз. 25/XII-41*
*Сәлам белән Вагыйз.*

Язылу вакыты—41 нең 25 декабре. Димәк, хат 63 ел элек язылган. Тарих өчен шактый зур вакыт. Бу вакыт эчендә күпме вакыйгалар булып узган, күпмесе инде онытылган, юкка чыккан. Ә бу гаптади дәфтәр битләренә химик каләм белән язылган, сугышчының күңел җылысын һәм яшәү өметен үзенә сыйдырган өчпочмаклы хат исән, югалмаган, сакланган.

Бу хатка мин авылдашыбыз Лотфиева Шәмсия ханымнарда тап булдым. Шәмсия Вагыйз кызы 45 ел Бәзәкә авылында фельдшер булып эшләде, I категорияле шәфкать туташы халыкка тырыш һәм намуслы хезмәт күрсәтте. Бүген ул лаеклы ялда.

Шәмсия ханым хатны, дөньядагы иң олы хәзинә кебек, саклап һәм назлап кына миңа бирде дә:

—Менә, әтинең гаиләбезгә калдырган иң зур байлыгы, кадерле истәлеге шушы хат була инде. Ул безнең өчен медаль дә, орден да, герой да булды,—диде ул, күз яшьләренә буылып.—Мин бит чыгышым белән Минзәлә районы Калмия авылыннан. Әтием Вагыйз Лотфиев 1912 елгы иде. Колхозда бригадир булып эшләде. Ул бик чибәр, таза, матур кеше булган.

Бу хат Вагыйз Лотфиевның гаиләсенә фронттан язган соңгы хаты була. Вагыйзнең әтисенең чәчләрен чаларткан, әнисенең күзләреннән ачы яшьләр агызган, хатынының йөрәген мәңгелек сагыш утына салган, ә кызын гомере буе «бәлки әти исәндер, ул бер кайтып керер» дигән уйларда, өметләрдә яшәткән соңгы хат, соңгы хәбәр, соңгы яңгырь...

Шәмсия апага хатны кире кайтарам. Ул аны, сак кына дәфтәр эченә тыгып, урынына куя.

—Бу хат безнең гомерлек юлдашыбыз булды. Әнием исән чакта аны бик еш кулларына алды, йөрәк турында тотты. Ә мин, шушы хат аша белгән әтием һәм үз кулларымда җан биргән әниемнең якты истәлекләренә багышлап дога укыйм,—дип тәмамлады сүзен хуҗабикә.

Әйе, мондый аналар, хатыннар, балалар күпме булды икән бу каһәр суккан сугыштан соң? Аларны кем исәпләгән дә, кем санаган соң? Ул ялгыз аналар, тол хатыннар бүген бик аз калды инде. Сугыш чоры балалары, сугыш ятимнәре үзләре дә 60-70 яшьтә инде.

Мин, Шәмсия ханым һәм аның әтисе, әнисе турындагы уйларымны дәвам итеп, бары шуны гына әйтә алам: аларның яудан кайта алмаган ирне, газиз әтине яратулары, өзелеп сагынулары, тилмереп көтүләре, «әти» дип бер әйтергә гомер буе ымсынып, хыялланып яшәүләре—барысы, барысы да батыр атага, тугры анага изге дога булып ирешеен, аларның рухлары шатлансын, сөенсен!

**Р.Мөхетдинова,**
Бәзәкә мәктәбе

# Әтиемнең энесе турында

Курбангалин Әнвәр Лотфиевич 1919 едла Минзәлә районы Калмия авлында мулла гаиләсендә туа. Авылда 4 классны бетергәч, бездән 8 чакырым ераклыктагы күрше Күзкәй авылына 6 ел җәяү йореп,10 классны тәмамлый. Бу 1937-38 уку елы, мәктәпнең беренче чыгарылышы була. Шул ук елны Казан Дәүләт педагогия институтына – КГПИ  укырга керә. Уку дәверендә аэроклубка да йөреп парашюттан сикерә. Ике ел укыгач сугыш башлана, ул сугышка китә. 1943 елны башы белән каты яраланып, аңсыз килеш госпитальгә озатыла. Бик озак дәваланганнан соң, демобилизовать итеп, авылга кайта. Сәламәтлеге якшылангач 1946 елны КГПИда укуын давәм итә һәм институтны “отлично”га тәмамлый. Кайткач аны үзе укыган урта мәктәпкә директор итеп билгелиләр. Һәм Минзәлә районы Күзкәй мәктәбендә югары классларда математика укыта.

1963 елны Курбангалин Әнвәрга “Халык мәгарифе отличнигы” дигән исем бирелә. Гомере буе шунда эшли. 1964 елның көзендә юл хәлакәтендә хәлак була. Әнвәр Лотфиевичны зурлап Минзәлә районы һәм күрше районнар соңгы юлга озаталар һәм Күзкәй авылында җирләнә.

Шәмсия Лотфиева 2016 ел.




КАДРЫ РЕШАЮТ ВСЕ!
/СТАЛИН/
I-й ВЫПУСК
КУЗКЕЕВСКОЙ СР. ШКОЛЫ
МЕНЗЕЛИНСКОГО Р-НА ТАССР.
1937-38 г.
УЧ. ГОД
XX





# ХАЛЫК МӘГАРИФЕ ОТЛИЧНИКЛАРЫ

*„Бездә халык укытучысы буржуаз җәмгыятьтә бервакытта да тормаган һәм тормый торган һәм тора да алмаячак югарылыкка куелган булырга тиеш. Бу — исбат итүләрне таләп итми торган хакыйкать".*

***В. И. Ленин.***



Өстән аска: Минзәлә районы, Күзкәй унберьеллык мәктәбе директоры Ә. Курбангалин, Казан-



1946—47 уку елы. Укытучылардан бер төркем (сулдан). 1 рәт: Анна Трифонова, Һава Гасимова, Әнвәр Корбангалин (директор), Х. Сәхабетдинова (завуч), Мәрьям Абдрахимова. 2 рәт: Рәүфә Гатина, Павел Кунакбаев, Рәйханә Гыйззәтуллина, Миндияр Фатихов, Марзия Муллахмәтова, Елизавета Харитонова, Нурмый Салахов.